| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань / Казан ш. **БОЕРЫК**

12.03.2026 224-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2024 елның 7 февралендәге 123-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Федераль милектә булган һәм Рәсәй Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яисә аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Рәсәй Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Рәсәй Федерациясе Су кодексының 03.06.2006 ел, № 74-ФЗ, “Су саклау зоналары чикләрен билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында” Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 31 октябрендәге 1459 номерлы карары нигезендә су объектларының яр буе яклау полосалары чикләре”, “Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында” 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 № 325 карары белән һәм Куйбышев сусаклагычы кушылдыгы Шарманка елгасының озынлыгы турындагы 16.10.2023 елдан № 2023.0311500002123000027 “Ашыт елгасының, Зөя елгасының исемсез кушылдыгының яр буе сызыклары (су объектлары чикләре), Татарстан Республикасының Арча, Буа, Яшел Үзән, Кама Тамагы муниципаль районнары территориясендә урнашкан Яңа Тура авылындагы Черки-дала Әнәле-Нурлаты, Лащи елгасы, Чилчә елгасы (Зөя кушылдыгы), Чуксы елгасы (Зөя кушылдыгы), Шарманка елгасы, исемсез күлләр су саклау зоналары чикләре һәм яр буе яклау полосалары чикләре урнашу урынын билгеләү” контракт кысаларында алынган белешмәләрне төгәлләштерү нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының “Татарстан Республикасы Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Актаныш, Әлмәт, Арча, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Кама Тамагы,

Минзәлә, Түбән Кама, Сарман, Тәтеш, Тукай муниципаль районнары территориясендә урнашкан Крутовка, Вертелевка, Чангара, Морквашинка, Шишрек, Саинка, Касыймов, Тоша, Иныш, Большая Тельца, Студенец, Кыят, 2 исемсез Киндеркә елгасы кушылдыгы, Түбән Кама сусаклагычының Белоус авылы янындагы исемсез кушылдыгы, Иске Идел күле, Стрелочный лог, Игәнә-суа, Игәнә, Гардалинка, Ржавец, Добромышка, Сурка, Томбарлы (Томбарлы), Шайтанка, Ашыт, Лащи, Чильча, Чуксы, Шарманка елгалары, Черки-Гришино авылы янында Зөя елгасының исемсез кушылдыгы су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе яклау полосаларын билгеләү турында”, 2024 елның 7 февралендәге 123-п номерлы боерыгына 1.30 пунктта түбәндәгеләрне бәян итеп: “1.30. Шарманка елгасы су саклау зонасының киңлеге - 50 м; яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м”, үзгәрешләр кертергә.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (А.Р. Гыйззәтуллина) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә урнашкан Шарманка елгасының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе яклау полосалары чикләре турында белешмәләрне дәүләт су реестрына кертү өчен Федераль су ресурслары агентлыгына, һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органы) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрергә.

3. Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В. Веселова) әлеге боерыкны татарчага тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (Р.А. Заһидуллин) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары О.В. Мандичевага йөкләргә.

Министр А.И. Җиһаншин